Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы утырышы

**Карар № 80**

Түбән Бәрәскә авылы 27.10.2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 60 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе” турында нигезләмәне юкка чыгару хакында**

“Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Әтнә районы прокуратурасының 2023 елның 18 августындагы 02-08-02-2023/Прдп269-23-20920010 номерлы протесты нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 60 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәне юкка чыгарырга (2020 елның 9 мартындагы 132 номерлы, 2020 елның 11 сентябрендәге 142 номерлы үзгәрешләре белән).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.